СОВЕТ НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

18 сентябрь 2019 ел № 1-44

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Тәкәнеш торак пунктында Куйбышев урамын, Урта Тәкәнеш торак пунктында Яшьлек урамын, Югары Тәкәнеш торак пунктында Үзәк урамын, Түбән Оча торак пунктында Беренче Май урамын, Яңа Оча авылында Октябрь урамнары юлларын вакташ җәеп ремонтлау;
- Түбән Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш, Югары Тәкәнеш, Түбән Оча, Яңа Оча торак пунктларындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Түбән Тәкәнеш торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар өчен куелган һәйкәлне төзекләндерү (койма кую, бояу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү).

« ӘЙЕ » « ЮК ».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы Р.Җ.Хәмизуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / Р.Җ.Хәмизуллин /

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НИЖНЕТАКАНЫШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001242